алмый, чөнки ризык-малны Аллаһы Тәгалә бер Үзе генә, Үзенең илаһи хөкеме-карары белән аерым кешегә, шәхескә бирә. Аллаһы Тәгалә: *«Әгәр адәм угылларының ризыклары бертигез булса, алар бер-берсе белән талашып, сугышып бетәрләр иде»,* – дигән. *«Өммәтем өчен иң курыкканымның да куркынычы – алар арасында мал арттырып, бер-берсеннән көнләшеп, бер-берсен кырып ташлаудыр»,* –дип Аллаһы Тәгалә хәбибе Мөхәммәд әл-Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәте өчен үзәге өзелгән. *«Өч төрле нәрсәдән беркем дә котыла алмас»,*– ди Рәсүл Әкрам бер хәдистә. Бу сүзләрнең мәгънәсе – «ул өч төрле нәрсәнең тәэсире һәркемгә дә тиячәк» дигән сүз. Ул өч нәрсә, Пәйгамбәребез әйтүенчә – фараз кылу (ягъни болай булырмы икән, тегеләй булыр микән, болай иткән булсам, тегеләй булыр иде...), шомлану һәм хөсетләнү. Шуңа күрә дә *«Фаразласаң – фаразлаганыңны үтәмә, шомлансаң – ул шомлануыңа бирелмә, көнләсәң – көнчелек артыннан иярмә»,* – дип өйрәтә дә Рәсүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Шул ук вакытта «саклангнны Ходай саклар» дию дә бик хак. Фаразлама – Аллаһы Тәгаләгә тапшыр, тәвәккәллә. Шомланма – Аллаһы Тәгаләнең әмеренә буйсын, бер эшкә тотынырга булдыңмы – җитез булып, үлчәп, уйланып тотын. Көнләшсәң: «Йә, Раббым! Булган, биргән нигъмәтеңә мең шөкранамын!» – дип, догаңны кыл! Берәүгә ярдәм итсәң, иткән ярдәмең турында кычкырма, аны бөтен дөньяга белгертмә!

*(“Дин вә йола” газетасыннан)*

# Сәүдә – яхшы кәсеп

Хәзер бу фаный дөньяны бар җирдә дә сәүдәгәрләр-алыпсатарлар басты. Алар бүген бары тик бер генә уй белән яшиләр – ничек кенә булса да акча табарга, керем кертергә. Күптән түгел мин авылның бер аксакалы белән шул хакта сөйләшеп утырдым. Ул менә мондый фикер әйтте: «Үз өеңдә, үз хуҗалыгыңда маңгай тиреңне түгеп, хәләл көчең белән җитештергән әйберләрне югарырак бәягә сата алсаң, гөнаһ түгел, ә менә кайдан булса да, арзанга алып кайтып кыйммәткә сату – зур гөнаһ. Чөнки синең аңа хезмәтең бер дә кермәгән», – диде.

«Җәвамигуль Кәлим» дигән китапның 50нче хәдисендә: «Кәсепләрнең яхшысы – изге сәүдә итү һәм адәм баласының кул көче, хәләл юл белән мал табуы – кәсепләрнең иң хәерлесе», – диелгән. Ә инде «сәүдәгәрләр акча, байлык артыннан чабалар, бу дәрес түгел бит» дигән сүзләргә мондый җавап кайтарыр идек. Һәрберебезгә мәгълүм, бу дөнья – кәсеп йорты, адәм балаларының төрлесе төрле һөнәр белән шөгыльләнә: кем укытучы, кем шофер, кем табиб, кем электрик һ. б. һәрберсе үз урынында кирәк.

Сәүдә кәсебенә килсәк, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм, гомумән, ислам шәригате аңа уңай караштa. Ләкин сәүдәдә гаделлек таләп ителә. *«Гаделлек белән бер-берсенә хыянәт итмичә эшләгән кешеләр арасында мин өченчемен, сезгә һәрвакыт ярдәм итүче, саклаучы булырмын»,* – ди Аллаһы Тәгалә. Ләкин сәүдә итүчеләрнең берсе икенчесенә хыянәт итсә, Аллаһы Тәгалә аларның араларыннан чыга, аларга риза булмый, дөнья-ахирәтләрендә бәхетсезлеккә юлыктыра.

Согуд Гарәбстанында, Төркиядә һәм башка чит илләрдә йөргәндә, шуны күрәбез: сатулашканда маңгаеңнан тир чыкканчы сатулашырга да мөмкин. Ләкин шуны истә тотарга кирәк: ахыр чиктә ике яклы килешү булырга, ике як та риза булып калырга тиеш. Әгәр дә сатулашып, үз бәяңне куйганнан соң, артык бер тиен генә үзеңә калдырсаң да, бу икенче якка хыянәт итү булып санала. Шуның өчен сатулашканча гына сатулаш та, аннан соң тиешле бәһасен бир.

Сәүдәгә кагылышлы тагын бер кагыйдә бар. Бер кеше икенче кеше белән бәя билгеләп сатулашып торганда, өченче кеше араларына керсә, дөрес түгел. Мәсәлән, алар әйберне биш сум белән сөйләшеп торганда, өченчесе «мин 5 сум 50 тиен бирәм» дип, араларына керсә, аннан да зур гөнаһка ия булучы юк.

Тагын бер мәсьәлә бар. Кайбер кешеләр, сатучылар бер җирдән арзанракка алып кайтып, монда кыйммәткә саталар, дип зарланалар. Ләкин чынлыкта исә бу – нигезсез. Монда без аларның әйберләрен бераз кыйммәтрәккә булса да аз-азлап алабыз. Ә шул аз гына әйбер өчен без еракка барсак, безгә ул бик күпкә кыйммәтрәк булыр иде. Сатучыларның да юл һәм башка чыгымнары була, шуңа да инде аннан бер сумга алып, монда да шул ук бер сумга сатсалар да, дөрес булмас иде. Алар безне тәэмин итәләр, һәм соңгы чиктә беркем дә көчләп сатмый, һәрберебез үзе сайлап алырга мөмкин.

*(“Дин вә йола” газетасыннан)*

# Таң догасы

*Бүләк иттең тагын бер якты таң,*
*Рәхмәтлемен сиңа, Раббым.*
*Бәхетем арта Синең хозурыңа*
*Якынлашкан саен бер адым.*

*Шул бер адым кешелеккә таба,*
*Мәңгелеккә таба юл яра.*
*Туры юлдан адаштырма берүк,*
*Сине җуйган - үзе югала.*

*Туар өчен рөхсәт иткән икән,*
*Рөхсәт итче яшәү өчен дә.*
*Кол һәм күндәм татар булып түгел,*
*Хөр, мөселман, кеше йөзендә.*

*Азатлыгын күрим Ватанымның,*
*Вә хөрлеген туган телемнең,*
*Кемнәр Синнән ни сорыйдыр, белмим,*
*Тумыштан мин шуны телимен.*

**Хәмид ВӘЛИДИ.**



№ 52 (1179), 22 декабрь 2012 ел

гаилә әгъзалары өчен ризык табу максатында хезмәт итә, төрле кыенлыкларны җиңә. Тормыш мәшәкатьләреннән арыгач, хатыны хозурында тынычлык таба, гаиләсендә бөтен арыганлыгы җуела.

Никах динебез күрсәтмәләренә муафыйк хәлдә төзелсә, аны саклау өчен хәрәкәт ителсә, әлбәттә, ул нык булачак, гаилә әгъзалары да бәхет-сәгадәттә яшәячәк.

Кызганыч ки, кайбер яшьләр никахка бик җиңел карыйлар, ашык-пошык төзелгән никахлары тиз арада таркала.

Әлбәттә, күп вакытта бу - никахның асылын белмәү нәтиҗәседер. Бу җәһәттән, җәмәгатьчелек никахның әһәмияте, изгелеге турында сөйләүдә-төшендерүдә тырышлыкны арттырсалар иде.

Егетләрне алдан ук гаилә башлыгы вазифасына әзерләргә – хәләл кәсеб өйрәтергә, гаилә тәрбияләүнең фарыз һәм бик әҗерле гамәл икәнлеген аңлатырга кирәк. Кызларга исә өй эшләрен чисталык, пөхтәлек белән үтәү Һәм яхшы күркәм мөгамәләле булу кирәклеген аңлату мөһим.

Ике яшь якты өметләр белән уртак тормыш башлаганда андый ниятне халыкка белдереп туй үткәрү кирәк. Әлбәттә, туй риясыз, исрафсыз үткәрелсә яхшы. Артык чыгымнар түгелү кемгә кирәк? Килен-кияүгә аннан файда бармы? Ул акчаны яңа башланган гаилә хәятенә тоту хәерлерәк.

Һичшиксез, шәргый яктан төзелгән никахларыбыз хөкүмәт билгеләгән тәртип белән дәүләт теркәлүен дә үтәргә, рәсми таныклык белән беркетелергә тиеш. Ул вакытта туачак балалар хаклары якланган, аныкланган булачак, күп проблемалардан яшьләр хали калачак.

### АЗ НӘРСӘ КИРӘК

Байлыкны көтеп утырып, яшьлекне уздыру һич дөрес түгел. Асылда кешегә яшәү өчен күп нәрсә кирәкми. Бу дөнья байлыгы әһәмияте турында шушы риваятьтән фикер йөртергә була: Һарун әр-Рәшиттән сорадылар: «Әй патшабыз, сахрада ялгыз калып сусызлыктан интегәсез, ди. Сезгә ул вакытта бер йотым су тәкъдим итсәләр, аның өчен нәрсә бирер идегез?» Һарун әр-Рәшит: «Хәзинәмнең яртысын бирер идем». Янә сорадылар: «Әй патшабыз, эчкә кергән бу бер йотым суның чыгып китүе дә бар. Чыгып китсен өчен нәрсәне тәкъдим итәр итегез?» Һарун әр-Рәшит җавап бирде: «Хәзинәмнең калган яртысын багышлар идем». Шунда хәкимнәр әйттеләр: «Алайса бөтен байлыгыңның кыйммәте бер йотым су икән».

Ныклап уйласак, бу гади риваятьтә хаклык күп: бер кеше бик авыр хасталанды. Якыннарын чакырып, акчаларын, алтыннарын уртага салып: «Нәрсә кылсагыз да, мине алып калыгыз», диде. Әмма кешенең язылган ризыгы тәмам ителсә, алтыннар ярдәм бирә алырмы соң?

Без акча тапсак, баесак, куанабыз. Ә ул байлык үзебезгә насыйп булырмы? Кодси хәдистә әйтелә: *«Әй адәм баласы, бәлки, бу дөньяда туплаган байлыгың варисларыңа калачак. Аннан туклану вә файдалану күбрәк башкаларга насыйп булачак. Ә аның хисабы вә үкенече исә сиңа төшәчәк. Кабердә сиңа фәкать яшәгән вакытта кылган яхшы гамәлләрең генә ярдәм бирәчәк».*

Бу турыда, кардәшләр, бу якты дөньяда булганыбызда онытмасак иде.

Аллаһы Тәгалә һәрбер яшь килен-кияүгә бәхет-сәгадәт, бәхтиярләрне чиксез итсен, гомерләрен ахырынача тынычлык, татулыктигезлектә үткәрүгә насыйп әйләсен.

**Вәлиулла хәзрәт ЯГЪКУБ.**
*(“Иман” газетасыннан)*

# Хакыйкать ачы була

“Туры сүз ачы булыр”, «Дус турысын сөйләр»... Борынгыдан килә торган мәкальләр бу. Чын дус үз дустына чын дөреслекне, никадәр ачы булмасын, әлбәттә, сөйләргә тиеш. Ни өченме? Дусты хатасын кабатламасын, үкенерлек эшләр эшләп, абруен төшермәсен өчен. Шуның өчен акыллы кешеләр туры сүзле дусларны ярата, аларны хөрмәт итә.

Кешеләрнең күбесе исә, киресенчә, туры сүзле бәндәне яратмый, хакыйкатьне сөйләгән дустан читләшергә тырыша. Шулай итеп, мондый кешеләрнең әйләнәсендә юмакайлар күбәя. Нәтиҗәдә хата өстенә хата өелә. Ахыр чиктә бу кешеләр дә акны карадан аера башлау дәрәҗәсенә җитә җитүен дә, әмма соң була, үкенү исә файда китерми.

Хикмәт иясе Бәязид әл-Бистами (875 елда вафат) тормышыннан бер вакыйга. Көннәрдән бер көнне Бәязид аркасына бер капчык он күтәргән олы хатын-кызны очрата. Бәязид аның янына килеп капчыкны ала да юл кырыена куя. Аннан соң шул тирәдә генә йөргән бер арысланга кулы белән ишарә итә. Теге арыслан, кулга өйрәтелгән юаш ат кебек, яннарына килә дә, Бәязид аның сыртына капчыкны сала. Өчесе бергә кузгалып китәләр.

«Капчыгыңны арысланнан илттергәнем өчен канәгатьме, әллә түгелме?» – дип сорый Бәязид хатыннан. Ләкин ни гаҗәп, хатын чыраен сыта, кашларын җыера: «Син һәм залим, һәм икейөзле кеше икәнсең! Ничек синнән канәгать булырга мөмкин?» – дип җавап кайтара хатын. Бәязид аптырап кала. Бу гаепләүнең сәбәбен сорый. Хатын болай аңлата: «Син залим кеше, чөнки арыслан, йөк хайваны булмаган килеш, синең аркада йөк күтәрергә мәҗбүр. Ягъни син аннан табигатенә капма-каршы килә торган эш эшләтәсең... Шул ук вакытта син икейөзле дә, чөнки миңа яхшылык күрсәтеп, нәфесеңнең теләгән үтисең. Хатын кешеләргә бу гаҗәеп хәлне сөйләр дә, шуннан соң абруем артыр, халык яхшылыкларыма хәйран калыр дип уйлыйсың!»

Шушы ачы, ләкин күпмедер дәрәҗәдә дөреслеккә дә туры килә торган сүзләр каршында Бәязид тынып кала, сүз көрәштерми. Хатынның